| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ ТИХОНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ТИХОНОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

Р Е Ш Е Н И Е К А Р А Р

2020 елның 21 августыннан № 158

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
«Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясендә үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 19 статьясы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2018 елның 5 сентябреннән 82 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск районы «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2013 елның 28 маеннан 7 номерлы Тихоново авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләреннән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләрен Россия Федерациясе Икътисадый үсеш Министрлыгының 2014 елның 01 сентябрендәге 540 номерлы Боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре Классификаторына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең 2020 елның 1 гыйнварындагы 1 номерлы гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 3 өлешнең II бүлегендәге 35 статьясында «Ж1» бүлегенең 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчемсез милектән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:

- индивидуаль торак төзелеше өчен;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге);
- участоклары булган блокланган бер гаилә йортлары;

- балалар бакчалары, мәктәпкәчә тәрбия бирүнең башка объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында бастырырга, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Тихоново авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Тихоново авыл җирлеге
Советы Рәисе А.М. Карманов